**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы**

# КАРАР №16

Кәрәкәшле ав. 15.11.2022 ел

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 23.05.2018 ел, №10 Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (редакциядә 27.12.2018 ел,№35)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 13 декабрендәге 2018 елның 28 мартындагы«Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» 182 санлы Татарстан Республикасында «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы контроль-хисап органнары рәисләренең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары хакында»гы 1222 санлы, Татарстан Республикасы министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 санлы Татарстан Республикасында «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы контроль-хисап органнары рәисләренең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары хакында»гы 881 санлы карары нигезендә, Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 маендагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 10 санлы карары белән расланган, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының айлык акчалата хезмәт хакының күләмен 2022 елның 1 октябреннән

1,04 тапкырга арттырырга.

2. Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 маендагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 10 санлы карары белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 тапкырга индексацияләү һәм аны 11 958,00 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча куярга: www.jutaza.tatar.ru

5. Бу карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
6. Әлеге карарны контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәрәкәшле авыл
җирлеге башлыгы: А.Г.Дәүләтгәрәев

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Для документов
СОВЕТ КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН